**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлегенең Рус Кырык Садагы авылында гражданнар җыены карары**

21 март 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлегенең Рус Кырык Садагы авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлегенең Рус Кырык Садагы авылы гражданнары җыенының 2023 елның 15 ноябрендәге 1нче номерлы карарының 2 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:.

"2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-торак пункт территориясен төзекләндерү ( кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу, (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, Рус Кырык Садагы авылындгы килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).".

2. Җыен нәтиҗәләрен Кырык Садак авыл җирлегенең Рус Кырык Садагы авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Кырык Садак авыл җирлеге башлыгы _________ В.Ф. Шаһиева

Халык җыены секретаре _________ Ф.Г. Миннегалиева